# Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
# Югары Стәрле авыл җирлеге Советы
# КАРАРЫ

Югары Стәрле авылы №21-12 «12» март 2021 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» карарына үзгәреш кертү хакында (14.08.2015 №141, 10.10.2018 №112-72, 24.06.2019 №139-86, 05.11.2019 №150-91,02.10.2020 №10-3 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге, «Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән

Югары Стәрле авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» карарына 14.08.2015 №141, 10.10.2018 №112-72, 24.06.2019 №139-86, 05.11.2019 №150-91,02.10.2020 №10-3 карарлар редакциясендә) 4 пунктның 7 пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«-авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга;».

2. Әлеге карар “Маяк” район газетасында басылып чыккан көннән соң, бер ай вакыт узгач, үз көченә керә һәм җир салымын 2020 елның 01 гыйнварыннан исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru. һәм «Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә торуны бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Сабирҗанова Л.С.